2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авылы җирлеге Рус Акташы авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫКАРАРЫ

23 ноябрь 2022 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташ авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлеге Рус Акташы авылы территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә: метеостанциядән алып Рус Акташы авылы зиратына кадәр юл участогын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, технадзор һәм милеккә рәсмиләштерү өчен түләү.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Рус Акташы авылы Төзүчеләр ур., 14 йорттерриториясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендәӘлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Рус Акташы авыл җирлеге башлыгы С. А. Белоногов